СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 266 от 09.11.2018
на № ________ от ____________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставын (19.12.2014, №281) “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга тәңгәл китерү һәм “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 маддәсенә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына ярашлы рәвештә, Саба муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставын яңа редакциядә кабул итү турында» 2014 елның 19 декабрендәге 281 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектын расларга (теркәлә).
2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты буенча җәмәгать тыңлауларын, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2006 ел, 21 ноябрь, 94нче карары белән расланган “Саба муниципаль районында җәмәгать тыңлаулары турында Нигезләмә”дә билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Байлар Сабасы штб., Г. Закиров урамы, 52 нче йорт адресы буенча Саба муниципаль районы Башкарма комитеты бинасының актлар залында 2018 елның 10 декабрендә 09.00 сәгатьтә үткәрергә.
3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына гражданнарның тәкъдимнәрен хисапка алу һәм аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен расларга.
4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр буенча тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләрне Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советына 2018 елның 10 декабрենә кадәр җибәрергә.
5. Бастырып чыгарырга:

- “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карар проектын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында;
- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына гражданнарның тәкъдимнәрен хисапка алу һәм аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында;
- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты буенча җәмәгать тыңлауларын үткәрү тәртибен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының юридик бүлеге начальнигы А.И. Миникәевка йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов

СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Советының
09.11.2018 ел, 266 нчы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр
проекты

**1.** Уставның 6 статьясының 1 пунктындагы 5 пунктчасына “муниципаль район чикләрендә торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына” сүзләреннән соң “юл хәрәкәтен оештыру” сүзләрен өстәргә;

**2.** Уставның 6 статьясының 2 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә, парковкалар (парковка урыннары) булдыру һәм эшләвен тәэмин итүне кертеп, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү, җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, юл хәрәкәтен оештыру, шулай ук Россия Федерациясе законнарына ярашлы рәвештә автомобиль юлларын куллану һәм юл эшчәнлеген оештыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

**3.** Уставның 6 статьясының 1 пунктындагы 17 пунктчасына “индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзүне яки реконструкцияләүне планлаштыру турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрлары билгеләнгән параметрларга туры килү һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруны рөхсәт итү турында хәбәрнамә, индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортынөң планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрлары билгеләнгән параметрларга туры килмәү һәм (яисә) индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруны рөхсәт итмәү турында хәбәрнамә, индивидуаль торак төзелеше объектлары яисә бакча йортлары җирлекләр территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрендә төзелгәндә яисә реконструкцияләнгәндә, төзелгән яисә реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге хакындагы законнар таләпләренә туры килүе яисә туры килмәве турында хәбәрнамә юллау, Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы жимерү турында карар, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү яисә аны рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында билгеләнгән чик параметрларына яисә капиталь төзелеш объектларының федераль законнарда билгеләнгән параметрларына карата мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында карар, максатчан билгеләнештә файдаланмый торган яисә Россия Федерациясе законнарын бозып файдалана торган җир кишәрлеген тартып алу турында карар кабул итү, үз

белдеге белән төзелгән корылманы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда җимерүне яисә аны билгеләнгән таләпләргә туры китерүне гамәлгә ашыру” сүзләрен өстәргә;

**4.** Уставның 6 статьясының 1 пунктындагы 16 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“16) район биләмәсендә каты көнкүреш калдыкларын туплау (шулай ук аерып туплау), җыю, ташу, эшкәртү, утильлләштерү, зарарсызландыру, күмү эшен оештыруда катнашу”;

**5.** Уставның 1 статьясының 1 пунктындагы 30 пунктчасына “(ихтыярыйлык (волонтерлык)” сүзләрен өстәргә”;

**6.** Уставның 6 статьясының 2 пунктындагы 13 пунктчасына “индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрлары билгеләнгән параметрларга туры килү һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруны рөхсәт итү турында хәбәрнамә, индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрлары билгеләнгән параметрларга туры килмәү һәм (яисә) индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруны рөхсәт итмәү турында хәбәрнамә, индивидуаль торак төзелеше объектлары яисә бакча йортлары шәһәр округлары территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрендә төзелгәндә яисә реконструкцияләнгәндә, төзелгән яисә реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге хакындагы законнар таләпләренә туры килүе яисә туры килмәве турында хәбәрнамә юллау, Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү турында карар, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү яисә аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карар, максатчан билгеләнештә файдаланмый торган яисә Россия Федерациясе законнарын бозып файдалана торган җир кишәрлеген тартып алу турында карар кабул итү, үз белдеге белән төзелгән корылманы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда җимерүне яисә аны билгеләнгән таләпләргә туры китерүне гамәлгә ашыру” сүзләрен өстәргә;

**7.** Уставның 7 статьясының 2 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 14 пункт өстәргә:

“14) “Кулланучылар хокукларын яклау турында” 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру”.

**8.** Уставның 19 статьясының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**9.** Уставның 19 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“19 статья. Җәмәгать тыңлаулары, җәмәгать фикер алышулары

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча муниципаль норматив хокукый актларның проектлары буенча районда яшәүчеләр катнашында фикер алышу өчен район Советы, район Башлыгы тарафыннан җәмәгать тыңлаулары үткәрелергә мөмкин.

2. Җәмәгать тыңлаулары халык, район Советы, район Башлыгы, Башкарма комитет Җитәкчесе инициативасы белән үткәрелә.

Халык яисә район Советы инициативасы белән үткәрелгән җәмәгать тыңлаулары - район Советы, ә район Башлыгы яисә Башкарма комитет Җитәкчесе инициативасы белән үткәрелгән җәмәгать тыңлаулары район Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

3. Җәмәгать тыңлауларына чыгарылырга тиеш:

1) район Уставы проекты, район Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм законнары нигезләмәләрен төгәл кабатлаган очраклардан тыш, Уставны бу норматив хокукый актларга тәңгәл китерү максатыннан, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив акт проекты;

2) район бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турында хисап;

3) районның социаль-икътисадый үсеш стратегиясе проекты;

4) районны үзгәртеп кору мәсьәләләре, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законның 13 статьясы нигезендә, районны үзгәртеп коруга район халкының, тавыш бирү юлы белән бирелгән, ризалыгы таләп ителгән очраклардан тыш;

4. Генераль планнар проектлары, җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектлары, биләмәне планлаштыру проектлары, биләмәне ызанлау проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берәрсенә үзгәрешләр кертүне караган пректлар, капиталь төзелеш объектын яисә җир кишәрлеген куллануга шартлы рөхсәт төренә рөхсәт бирү турында карар проектлары, рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан читкә чыгуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү турында карар проектлары; расланган җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре булмаган очракта җир кишәрлеген һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән бер куллану төреннән икенче шундый куллану төренә үзгәртү мәсьәләләре буенча җәмәгать тыңлаулары яисә җәмәгать фикер алышулары үткәрелә. Аларны оештыру һәм үткәрү тәртибе, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында гамәлдәге законнарны исәпкә алып, әлеге Устав һәм (яисә) район Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

5. җәмәгать тыңлауларын яисә җәмәгать фикер алышуларын үткәрү турында карар, закон белән башкача каралмаса, тиешле орган яисә вазыйфаи зат тарафыннан муниципаль норматив хокукый акт проекты каралырга тиешле көннән 20 көннән дә соңга калмыйча, кабул ителергә тиеш;

6. җәмәгать тыңлауларын яисә җәмәгать фикер алышуларын үткәрү турында карар, үткәрү вакытын һәм үткәрү урынын күрсәтеп һәм җәмәгать тыңлауларына яисә җәмәгать фикер алышуларына чыгарылган тиешле муниципаль норматив акт проекты, гамәлдәге законнар белән башкача каралмаса, җәмәгать тыңлауларын үткәрүгә 7 көннән дә соңга калмыйча, бастырып чыгарылырга (игълан ителергә) тиеш;

7. җәмәгать тыңлауларын яисә җәмәгать фикер алышуларын үткәрү турында карар бастырып чыгарылган көннән алып аларны үткәрү көненә кадәр район халкы район Башлыгына җәмәгать тыңлауларына яисә җәмәгать фикер алышуларына чыгарылган мәсьәлә буенча язмача тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр, шулай ук җәмәгать тыңлауларына яисә җәмәгать фикер алышуларына чыгарылган мәсьәлә буенча муниципаль норматив хокук актына төзәтмәләр һәм башка тәкъдимнәр юлларга хокуклы. Район Башлыгы кергән тәкъдим һәм күрсәтмәләрне гомумиләштерүне оештыра. Күрсәтелгән тәкъдим һәм күрсәтмәләр җәмәгать тыңлауларында яисә җәмәгать фикер алышуларында катнашучылар игътибарына җиткерелә;

8. җәмәгать тыңлаулары яисә җәмәгать фикер алышулары муниципаль норматив хокукый акт проекты караласы көнгә кадәр 7 көннән дә соңга калмый, әгәр гамәлдәге законнар белән башкача каралмаса, үткәрелә. Җәмәгать тыңлаулары яисә җәмәгать фикер алышулары белгечләрне, экспертларны, кызыксынган затларны чакырып

үткәрелә. Җәмәгать тыңлаулары яисә җәмәгать фикер алышуларында районда яшәүче һәркем катнашырга хокуклы;

9. җәмәгать тыңлаулары яисә җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләре буенча җәмәгать тыңлаулары яисә җәмәгать фикер алышуларына чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проектын кабул итү компетенциясенә кергән вазыйфаи зат яисә җирле үзидарә органы тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш булган бәяләмәләр кабул ителә;

10. җәмәгать тыңлаулары яисә җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләре, кабул ителгән карарларның дәлилле нигезләмәләрен дә кертеп, җәмәгать тыңлаулары яисә җәмәгать фикер алышулары үткәрелгән көннән 5 көн дә соңга калмыйча, бастырып чыгарылырга (игълан ителергә) тиеш;

11. җәмәгать тыңлаулары яисә җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе район Советы белән расланган җәмәгать тыңлаулары яисә җәмәгать фикер алышулары турында Нигезләмә белән билгеләнә;

12. Әлеге статьяда күрсәтелгән сроклар, әгәр гамәлдәге законнар белән җәмәгать тыңлаулары яисә җәмәгать фикер алышуларына башка сроклар билгеләнмәгән очракта кулланыла.";

**10.** Уставның 28 статьясының 1 пунктына түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац өстәргә:

"Муниципаль район составына кергән җирлекләр Башлыкларыннан торган район Советы депутаты һәм җирлек Советлары депутатлары вәкаләтләре муниципаль район составына кергән җирлек Башлыгы вазыйфасына керешкән көннән яки җирлек Советы депутатын, әлеге җирлек кергән район Советы депутаты итеп сайлап куйган көннән башлана һәм яңа сайлап куелган җирлек Башлыгы вазыйфага керешкән көннән яки әлеге җирлектән район Советы составына чираттагы сайлап кую турындагы карар көченә кергәннән туктатыла.";

**11.** Уставның 28 статьясының 6 пункты 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) Россия Федерациясе Президенты яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә түләүсез нигездә оешманың коллегиаль идарә органнары составында катнашудан тыш; учредитель булган оешма вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән башкару яисә муниципаль милек булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актларга туры китереп, түләүсез нигездә идарә органнарында һәм муниципаль берәмлек учредитель (акционер, катнашучы) булган оешманың ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлекнең мәнфәгатьләрен яклаудан; федераль законнар белән каралган башка очраклардан тыш, шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерциячел оешма белән идарә итүдә яисә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, сәяси партия белән идарә итүдә катнашу; башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләре съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу моңа керми);";

**12.** Уставның 45 статьясының 1 пункты 3 пунктчасындагы алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“– район территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым-аерым туплау), жыю, ташу, эшкәртү, үтильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнаша»;

**13.** Уставның 45 статьясының 1 пункты 4 пунктчасындагы икенче абзацка “муниципаль район чикләрендә торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына” сүзләреннән соң “юл хәрәкәтен оештыру” сүзләрен өстәргә;

**14.** Уставның 45 статьясының 5 пункты 9 пунктчасындагы тугызынчы абзацка “(ихтыярыйлыкка (волонтерлыкка)” сүзләрен өстәргә;

**15.** Уставның 74 статьясының 3 пунктына түбәндәге редакциядәге икенче һәм өченче абзацлар өстәргә:

“Муниципаль хокукый актларны һәм җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең тулы тексты район биләмәсендә таратыла торган даими матбугат басмасында беренче тапкыр басылып чыгу аның рәсми басылып чыгуы дип атала.

Җирле үзидарә органнары муниципаль хокукый актларны һәм килешүләрне рәсми бастырып чыгару (игълан итү) өчен шулай ук челтәр басманы да файдаланырга мөмкин. Муниципаль хокукый актның тулы тексты рәсми челтәр басмада басылып чыккан (урнаштырылган) очракта, аның күләмле графика һәм таблицалар булган кушымталары матбугат басмасында урнаштырылмаска да мөмкин.”;

**16.** Уставның 74 статьясының 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Район Советының район бюджеты турында, аның үтәлеше турында хисап хакында, җирле салым һәм җыемнарны билгеләү турында, район Советы, район Башлыгы, район Башкарма комитеты кабул иткән башка норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр, тарату федераль закон белән чикләнгән мәгълүматлары булган муниципаль хокукый актлар яки аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, кул куелганнан соң җиде көн эчендә рәсми бастырылырга (игълан ителергә) тиеш.”;

**17.** Уставның 74 статьясының 9 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9. Муниципаль хокукый актларны, җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне рәсми бастыру (игълан итү) түбәндәгеләр аркылы гамәлгә ашырыла:”

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Советының
09.11.2018 ел, 266 нчы карары белән
РАСЛАНДЫ

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына гражданнарның тәкъдимнәрен хисапка алу һәм аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына тәкъдимнәр 422060, Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Байлар Сабасы ш.т.б., Г. Закиров урамы, 52 йорт, 315 каб. адресы буенча язмача рәвештә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советына Саба муниципаль районы Советының оештыру бүлеге начальнигына тапшырыла.

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.30 сәгатькә кадәр «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында игълан ителгән көннән кабул ителә.

2. Чыгыш ясау хокукы белән җәмәгать тыңлауларында катнашуга гаризалар 422060, Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Байлар Сабасы ш.т.б., Г. Закиров урамы, 52 йорт, 315 каб. адресы буенча (конвертта “Устав буенча фикер алышу” тамгасы белән) шәхсән тапшырыла яисә почта аша юллана.